**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **11.12.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге
составына керүче Күктәкә авылында
2020 елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Күктәкә авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Тымытык авыл җирлеге Күктәкә торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

-Күк-Тәкә авылында Совет ур. буенча вак таш белән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Тымытык авылында юл билгеләре сатып алу;
- Күк-Тәкә авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Күк-Тякә авылы территориясендә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Күк-Тәкә авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;;
- Күк-Тәкә авылында спорт чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукңиясе сатып алу;
- Күк-Тәкә авылындагы юлларны кардан чистарту;
- Күк-Тәкә авылында җәйге чорда территорияләрне чабу;
- Күк-Тәкә авылында коры агачлар, куаклар киселү;
- Күк-Тәкә авылында урам исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу (әзерләү) һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- Күк-Тәкә авылы зиратын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б нчы йорт, Күктәкә авылы, Ленин урамы, 40 нчы йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тымытык авыл җирлеге Башлыгы Э.Х. Гыйләҗева